**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 13.01.2020** **№ 89**

**Мәктәп автобус маршрутын ачу буенча
комиссия төзү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 03 августындагы 615 нче номерлы "Мәктәп автобус маршрутын ачу турында Нигезләмәне раслау турында" карары нигезендә, 2019/2020 уку елында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртү иминлеген тәэмин итү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Дөбьяз авылы - Казаклар авылы - Дөбьяз авылы» мәктәп автобус маршрутын ачу өчен Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 23 октябрендәге 2492 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениеләренең мәктәп автобуслары хәрәкәтенең планлаштырылган маршрутларын тикшерү комиссиясе эше тәртибен раслау турында» карары нигезендә эш итүче комиссия (килешү буенча) төзергә:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Н.К. | -башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигы, комиссия рәисе; |
| Яруллина М.Р. | -«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигы урынбасары, комиссия секретаре; |
| Әсәдуллин А.Р. | - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ бүлеге начальнигы; |
| Тарасова А.С. | - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе секретаре; |
| Борханов Р.Х. | - «РегионТрансСервис» ЖЧЖ механигы |

2. Комиссиягә 2020 елның 20 январена кадәр мәктәп автобус маршрутын кабул итүне тәэмин итәргә.

| База мәктәбе исеме | Маршрут |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | «Дөбьяз авылы - Казаклар авылы - Дөбьяз авылы» |

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Р.Б. Хәсәновка тәкъдим итәргә:

-расланган форма нигезендә мәктәп автобус маршруты паспортын эшләргә;

-мәктәп укучыларының чыгу графигын эшләү;

-балаларны уку урынына китергәндә һәм кире кайтканда озату өчен дәрестә һәм дәрестән тыш вакытта җаваплы башкаручыларны билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф бүлеге начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин